| СОВЕТ КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Күгәй авылы

**2024 елның 5 июне** **№163**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәте өчен түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (2022елның 26 сентябрендәге 83 номерлы,2022 елның 30 декабрендәге 98 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең, муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә Күгәй авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәте өчен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен билгеләү турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге советы карарына (2022елның 26 сентябрендәге 83 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 98 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - Карар):

1) 1 нче пунктта:

1.1) беренче абзацта «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзен «2024 елның 1 июленнән»сүзләре белән алыштырырга;

1.2) Икенче абзацта 17 390 (унҗиде мең өч йөз туксан) сум күләмендә һәм 13 420 (унөч мең дүрт йөз егерме) сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү сүзләрен 18 260

(унсигез мең ике йөз алтмыш) сум күләмендә һәм 19 569 (унтугыз мең биш йөз алтмыш тугыз) сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү сүзләре белән алыштырырга »;

2). 2 нче пунктта:

2.1) беренче абзацта «2023 елның 1 гыйнварыннан» сүзен «2024 елның 1 июленнән» сүзләре белән алыштырырга;

2.2) Икенче абзацта 17 390 (унҗиде мең өч йөз туксан) сум күләмендә 18 260 (унсигез мең ике йөз алтмыш) сум күләмендә сүзләре белән алыштырырга;

3) 3 пунктта «2023 елның 1 гыйнварыннан» дигән сүзләрне «2024 елның 1 июленнән»дигән сүзләр белән алыштырырга;

4) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Күгәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен түбәндәге редакциядә бәян итәргә

Кушымта
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Советы карарына
2024 елның 5 июне №163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ ЗУРЛЫГЫ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфаларының исемнәре** | **Айлык күләме вазыйфаи оклад, сум** |
|---|---|
| Авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) | 17 720 |
| Әйдәп баручы белгеч | 14 789 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

**Күгәй авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Ф. Х. Хисаметдинова**